ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮРӘЗМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ LIII СЕССИЯСЕ

**КАРАР № 2**

Үрәзмәт « 03 » февраль 2020 ел

**Үрәзмәт авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 ноябрендәге 3 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә,Үрәзмәт авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2018 елның 28 ноябрендәге 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктның 1 пунктчасының 3 абзацын төшереп калдырырга;

б) 2 пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,1 %;»

1. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (http://muslumovo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Үрәзмәт авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2020 елның 3 мартыннан җир салымын исәпләүгә бәйле рәвештә хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Үрәзмәт авыл җирлеге Башлыгы Ә.Г.Закирянов